ГЛАВА
МАЛЬБАГУШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Нефтяников, д30, с.Мальбагуш,
Азнакаевский муниципальный район 423330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МӘЛБАГЫШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ

Нефтьчеләр ур., 30 нче йорт, Мәлбагыш
авылы, Азнакай муниципаль районы, 423330

Тел./факс(885592)3-77-90,3-77-91; E-mail:Malb.Azn@tatar.ru,

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«11» октябрь 2023 ел № 3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Каменка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Каменка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 21 октябренә билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Каменка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 21 октябрь 2023 ел 11.00 сәг.тән 12.00 сәг.кадәр;

- үткәрү урыны – Каменка авылы, Җәлил ур. , 2 нче йорт;

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2023 елның 15 октябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Мәлбагыш авылы, Нефтяниклар урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Каменка авылы, Җәлил урамы, 1 нчы йорт ; Мәлбагыш авылы Җәлил урамы 2 нче йорт, Түбән Якый авылы Кашапов урамы 23 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын бирергә;

- Каменка торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Каменка торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш Мәлбагыш авыл җирлеге Каменка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Каменка авылында юлларны кардан чистарту(килешү буенча түләү);

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Мәлбагыш авылы, Нефтяниклар урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетында , Мәлбагыш авылы Җәлил урамы 2 йорт; Түбән Якый авылы, Кашапов урамы, 23 нче йорт ; Каменка авылы Җәлил урамы 1 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. урнаштырырга

4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башлык: А.Й.Әхмәтшин